ПЕНСИЯЛӘР АРТА, хезмәт күрсәтү уңайлана

> 2



ЧИК БУЕНДА Татарстан таможнясы узган елга хисап тотты

> 3

ТАТАР ТЕЛЕН өйрәтүче мари укытучысы: «Укучыларым дәрескә теләп йөри»

> 4

КОНВЕРТЛАР АЧЫЛДЫ: әдәби әсәрләр бәйгесенең «Роман» жанрында җиңүчеләр билгеле

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 15 (28788) | Чәршәмбе | 2 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ӘЙТМӘ СИН АВЫР СҮЗ...

Тәкъдим

Мәктәпләрдә укучыларга борчыган сорауларын язып салыр өчен «кара» тартмалар барлыкка килергә мөмкин. Чиләбе өлкәсендәге Чибәркүл шәһәренең укучы активистлары мондый тәкъдимне Россия Мәгърифәт министрлыгына җиткергән. Мондый тартмалар бала күңелендәге үпкәләрне киметә алырмы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Активистлар фикеренчә, ышаныч әрҗәсенә теләсә кайсы сорауны, психологка үтенечне исемне күрсәтмичә язып булачак. Бу – җәберләү турында сөйләттерүнең бердәнбер юлы дип саный алар. Бүген бит укучыларның барысы да хис-кичерешләрен психологка барып сөйләргә батырчылык итми. Психологка да ышанамы әле ул? Ә бу очракта тартмага җыелган борчуларны социаль роликлар аша күрсәтеп тә хәл итеп булачак дип ышана идея авторлары. Мондый яңалык балалар һәм олылар арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытачак. Һәрхәлдә, яшьләр шулай уйлый.

– Яхшы фикер бу, – ди Алабуга районындагы Хлыстово мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы, «Мобиль укытучы» грантын откан Ольга Пермина. – Үсмерләр бит теләсә кемгә ачылырга яратмый, ә чит кешегә бөтенләй. Үзләренең үпкә, курку, борчуларын әйтеп язганда, андый хисләрдән арына алачаклар.

Балтач районының Салавыч күппрофильле лицее директоры Нурсил Заһидуллин әйтүенчә, аларда мондый тартма күптән куелган инде. Аны гел ачып карап торалар, тик хат салучылар гына юк икән. Мәктәбен әйтергә теләмәгән Ләлә Галиева исә, мондый тартмалар авылга караганда, шәһәр җирендә күбрәк кирәк, ди.

– Шәһәрдә балалар бер-берсен кыерсыту, укытучылар белән укучылар арасында аңлашылмаучанлык барлыкка килү очраклары шактый. Кайбер мәктәпләрдә меңнән артык бала укый. Директор андагы хәлләрне каян белеп бетерсен? Психологның да шулкадәр укучы белән эшли алуы икеле. Яшерен тартма исә барлык проблемаларны хәл итәргә булышачак. Әлбәттә, язсалар инде. Авылда бөтен нәрсәне дә контрольдә тотабыз. Шәһәрдә исә күршесендәге хәлне дә белмиләр хәтта, – ди укытучы.

Мамадыш районының Түбән Ушма мәктәбен тәмамлаган Марат Бобоеров бүген Санкт-Петербург дәүләт университетында белем ала.

– Мин моны хуплыйм, – ди Марат. – Кечкенә чагында баланы җәберлиләр икән, аның үзбәясе түбәнәя, ул үчле булып үсәчәк. Бу хәлләр күңелсезлек белән тәмамланырга мөмкин. АКШтагы «Колумбайн» мәктәбен генә искә төшерик: ике баланы яратмаганнар, рәнҗеткәннәр. Шуңа күрә алар җинаять юлына баскан. Психологлар, барысын да ачыклап, борчуларны кичерергә ярдәм итәргә тиеш.

Әлеге тәкъдим турында Нидерландта яшәүче якташыбыз Гөлзирә Гаязованың да фикерен белештек. Анда тартмалар кую гадәте юк икән.

– Мин якшәмбе мәктәбендә эшләдем. Бер генә баланың да тәртипсезләнгәнен күрмәдем. Әгәр берәр хәл килеп чыкса, укучы укытучысы белән ачыктан-ачык сөйләшә, барысын да аңлата. Мөнәсәбәтләрне җайлау өчен бакчадан, башлангыч сыйныфтан ук аерым дәресләр булдырылган, – ди Гөлзирә Гаязова.

– Казанның 171 нче мәктәбе психологы Оганна Акопян активистлар фикере белән килешә.

– Һәр үсмернең үз борчуларына җавап табарга теләгән минутлары бар. Бу очракта ышаныч почтасы булыша ала. Ни өчен дигәндә, бар бала да үз проблемаларын ачыктан-ачык белдерә алмый. Хәзер күп кенә мәктәпләрдә килештерү хезмәтләре булдырылган. Анда укучылар, җитәкчеләр белән бергә, балалар һәм укытучылар арасындагы бәхәсле хәлләрне чишү, буллинг күренешләрен, үсмерләр арасында хокук бозу очракларын булдырмау буенча эш алып бара, – ди Оганна Акопян.

Сәрия МИФТАХОВА

Белгеч фикере

Илсөя СӘГЪДИЕВА,
Татарстан Мәгарифне үстерү институты белгече:

> Мин тартма урынына, хәзерге заман технологияләренә бәйле башка форматны сайлар идем. Яшьләрне җәлеп итмәс ул. Бала үз күңелендәгесен ышанып тапшыра ала торган мавыктыргыч заманча чара кирәк. Мондый тартмаларга укучыларның 20 проценты нәрсәдер язып салырга мөмкин. Тик проблеманы әйтеп түгел, кызык өчен. Проблемасы булганы анда язмас дип уйлыйм. Аның ел буе эленеп торуының да кирәге юктыр. Озак эленеп торса, игътибар итми башлаячаклар. Әйтик, психологлар көнендә, бер-беребезгә ярдәм итү акцияләре булганда куярга мөмкин.

Урманнар чистара

Быел Татарстанда 5,8 мең гектар мәйданда урманнар корыган, чирле агачлардан чистартылачак. Урман хуҗалыгы министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, агач-куакларны корткычлар һәм чирләрдән саклау максатында кисү-чистарту эше ел дәвамында алып барылачак. Юллар, шәһәр-авыллар, шулай ук социаль объектлар тирәсендәге урман өлешләрен аерым игътибар үзәгенә алу күздә тотыла. Ә инде кисү-чистарту тәгәлләнгәннән соң бушап калган урыннарга яшь агачлар утыртылачак. Бу эшләрнең барысы да «Экология» илкүләм проектының «Татарстан Республикасында урманнарны саклау» төбәк проекты буенча башкарылачак.

Орлыкка акча бирелә

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга орлыклар сатып алу өчен 10 миллион сум бирелә. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Наил Залаков әйтүенчә, быел кулланучылар кооперациясе аша халыктан яшелчә сатып алып, аны кибетләргә урнаштыру күздә тотыла. Бу җәһәттән зур һәм җирле сәүдә челтәрләре белән килешүләр төзеләчәк.

Наил Залаков сүзләренә караганда, халыкның төп азык-төлек белән тәэмин ителеше, яшелчәдән тыш, 100 процент һәм аннан күбрәк. Яшелчәгә бәйле төп проблема – беткән саен аны сәүдә челтәренә китереп тору өчен, саклау урыны булмау. Шуңа күрә быел яңа яшелчә саклагычлар проектлауга акча бүлү карала. Шул ук вакытта министрлык республикада җитештерелгән товарларның кибет киштәләренә эләгү-эләкмәвен күзәтеп тора. Киштәләрдәге сөтнең 70 проценттан артыгы, катыкның 95 проценты чамасы, каймак һәм эремчекнең 70 проценттан күбрәге, икмәк-күмәч ризыкларының 85–95 проценты – Татарстанныкы.

Волонтерлар туплый башлыйлар

Волейбол буенча дөнья чемпионаты быел Россиянең ун шәһәрендә, шул исәптән Казанда узачак. Аны оештыру өчен 21 февральдә волонтерлар җыя башлыйлар. Ярышларга әзерләнү һәм аны үткәрүгә барлыгы 18 юнәлеш буенча 3500дән артыграк волонтер җәлеп итү күздә тотыла. Кандидатлар чемпионатны оештыручы шәһәрләрнең волонтерлык үзәкләрендә сайлап алыначак. Ярышларга кадәр кандидатка 18 яшь тулган булырга тиеш. Моннан тыш инглиз телен белү, команда белән эшләү осталыгы исәпкә алыначак. Волонтерлар сафына эләгү өчен турнирның оештыру комитеты сайтында махсус бүлектә заявка калдыру шарт.

Исегезгә төшерәбез: 2022 елда волейбол буенча дөнья чемпионаты 26 августтан 11 сентябрьгә кадәр узачак. Анда 24 команданың катнашуы көтелә.

Февраль бураннары

Февраль ае Казанда кар-бураннан, аномаль җылы һавадан һәм һава басымы уйнаудан башланып китте. КФУ экология һәм табигатьтән файдалану институтының метеорология кафедрасы мөдире Тимур Әүхәдиев «Татар-информ» хәбәрчесенә әйткәнчә, хәзер безгә көнбатыштан циклон үтеп кергән. Шуңа күрә кар ишеп явачак. Айның беренче декадасында тәүлеклек уртача температураның нормадан сигез градуска югарырак булуы фаразланыла. Якын көннәрдә Казанда уртача температура −11,5 градус тәшкил итәчәк. Әүхәдиев сүзләренә караганда, метеорологлар фаразлары буенча, быел февраль аенда шәһәрдә һава температурасы нормадан бер градуска югарырак булачак. Норма буенча айлык уртача температура −10,4 градус булыр дип фаразлана. Узган елның шушы вакытында башкалабызда аномаль суык (нормадан 5 градуска түбән) булган.

«Казанда яшәүчеләрнең февраль башында моның кадәр кар көртләрен 2011 елдан бирле күргәннәре юк иде әле», – дигән белгеч. Ул чагында кар биеклеге 88 см тәшкил иткән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

COVID – 19

Саулык та, бердәмлек тә сынала

Куркыныч саннар кимеми. Бер тәүлек эчендә генә дә республикада коронавирус белән авыручылар саны 777гә җиткән. Шуның 67се – балалар. Чагыштыру өчен: әле бер атна элек кенә республикада тәүлегенә 297 кешедә ковид ачыкланган булган.



«Татар-информ»

Татарстанның Коронавируска каршы көрәш буенча оператив штабыннан хәбәр итүләренчә, хәзерге вакытта республика хастаханәләренә бер тәүлек эчендә – 18 меңнән артык, «122» «кайнар элемтәсе»нә – 4 меңнән артык, «ашыгыч ярдәм» хезмәтенә 3 меңнән артык шалтырату килеп ирешә. Мөрәҗәгать итүчеләргә җавап бирү өчен медицина уку йортларында белем алучы студентларны җәлеп итәләр.

Коронавирус белән авыручыларны 55 медицина оешмасында дәвалыйлар. «Республикада авыручылар һәм хастаханәдәге урыннар саны да – күз уңында. Оператив штаб бу саннарны көн саен Татарстан Президентына җиткереп тора», – диелә хәбәрдә. 31 гыйнварга алынган мәгълүматларга караганда, хәзерге вакытта республикада коронавирус белән авыручылар өчен 3912 урын әзерләнгән. Шуларның 82,8 проценты авырулар белән тулган. Вазгыять катлаулана калса, урыннар саны арттырылачак. Медицина оешмалары барлык кирәкле җиһазлар, материаллар, дарулар, медицина хезмәткәрләре өчен кирәкле шәхси саклану чаралары белән тулысынча тәэмин ителгән, дип ышандыралар.

Ковид дигән зәхмәт аңа каршы көрәшкән белгечләрне дә аямый. Бүген медицина хезмәткәрләре арасында да коронавирус белән авыручылар шактый. Шөкер, аларны вакытлыча алмаштырып торырга кеше бар. «Авыруларга ярдәм күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә кытлык юк», – дип ышандыра белгечләр. Оператив штаб мәгълүматларына караганда, бүген республикада ковид белән авырган кешеләргә 15 меңнән артык медицина хезмәткәре, 875 «ашыгыч ярдәм» йөртүчесе хезмәт күрсәтә. Мәкерле чиргә каршы көрәшкә 4250 волонтер җәлеп ителгән. Алар республика халкына медицина һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтүгә үз өлешен кертә, хастаханәләрдәге кабул итү бүлекләрендә, реанимациядә, «кызыл зона»да эшләүче табиб һәм шәфкать туташларына ярдәм итә. Моннан тыш волонтерлар ярдәмгә мохтаҗ өлкәннәргә кирәкле дарулар да алып кайтып бирә.

Сүзгә-сүз

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,
язучы:

Язучыда гына түгел, һәр кешенең эчендә бала утырырга тиеш дип саныйм. Ул – ихласлык дигән сүз. Бала бит ялганны, ниндидер хәйләне кабул итми. Әдәбиятта иң авыры – балалар өчен язу, чөнки безнең яшьтә хәйлә кормыйча гына язу бик кыен. Ә бала бер ялган тойса, ул аны укымый. Көчләп ятлатсалар да, ул аны бик тиз оныта. Әгәр яратса, сөйләгәндә күзләреннән очкын чыга.

(«Шәһри Казан» газетасына әңгәмәдән)

ОЛИМПИАДА – 2022



4 февральдә Пекинда XXIV Кышкы Олимпия Уеннары башлана.

109 ....комплект медаль
15 ....спорт төре
91 ....команда
3000 ....спортчы
15 ....спорт корылмасы



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ОТТАВАДАН КАНБЕРРАГА КАДӘР

Дөнья илләрендә социаль протест яңадан алгы планга чыга. Бу юлы көрәш сызыгына Канадада ерак арага йөк ташучы автомобиль йөртүчеләр басты. «Азатлык конвое» дип аталган машиналар колоннасы илнең төрле почмакларыннан Канада башкаласы Оттавага килеп җитте һәм Премьер-министр Джастин Трюдодан пандемиягә каршы чикләүләрне йомшартуны таләп итә. Либераллар хөкүмәтен җитәкләгән Трюдо үзенең коронавируска каршы аяусыз көрәше белән танылды. Илдә ул керткән чараларга каршылык хәрәкәте көчәеп, хәл кискенләште, Премьер башкаладагы резиденциясен ташлап качарга мәҗбүр булды. Инде өченче көн Оттава урамнары меңләгән йөк автомобиле белән тулы, протест белдерүчеләр таләпләре үтәлмичә чигенмәскә вәгъдә итәләр. Җиңелгән очракта гыйсъянчыларны зур төрмә сроклары көтә, чөнки гамәлләре террорчылык акты дип саналачак. Бу көрәшне кискенләштерә, компромиссыз итә. Әлегә ике якның берсе дә ташламаларга барырга җыенмый.

Канада дальнобойщиклары үрнәгендә Европа йөк ташучылары да протестка әзерләнә. Италия, Нидерландтан һәм башка Көнбатыш илләреннән «Азатлык конвое» формалаштыру турында хәбәрләр ишетелә. Аеруча кырыс чаралары белән бөтен дөньяга танылган Австралиядән дә йөк ташучылар протестына әзерлек турында мәгълүматлар алырга мөмкин.

Пандемия исә үзенең кыскычларын йомшартырга бик җыенмый. Израильнең Сәламәтлек саклау министрлыгы үткән атнада COVID-19 китереп чыгарган үлемнәр санының 38 процентка артуы хакында рәсми игълан ясады. Япониядән өлкән яшьтәге пациентларның «омикрон» аркасында катлаулы авырулары хакында хәбәр итәләр. COVID-19 диагнозы белән үлүчеләр саны дөньяның уртача күрсәткечләреннән 2,7 тапкыр югарырак булган Бөекбританиядә исә чикләүләрне алырга җыеналар. Премьер-министр Борис Джонсон үткән атнада коронавируска каршы гадәттән тыш көрәш чараларын туктату хакында игълан итте. Финляндия Премьер-министры Санна Марин да февраль аеннан барлык чикләүләрнең дә бетерелүен белдерде. Гомумән, планетада «омикрон» дулкыны акрынлап чигенәчәгенә күпчелек белгечләр шикләнми. Әйе, яңа штамм бик күп сандагы кешене берьюлы иңләп ала, әмма чагыштырмача җиңел үтә. Гадәттән тыш кырыс чаралар күрүгә карамастан, әледән-әле коронавирус учаклары кабынып торган Кытай Олимпиада уеннарын тамашачылар катнашында үткәрергә әзерләнә. Бу пандемия куркынычы элекке төсле үк шик уятмавын дәлилли. Дөньяда коронавируска бәйле булмаган икътисади кыенлыклар баш калкытып ята. ОПЕК+ нефть чыгару темпларын кызулата алмыйча интегә. «Кара алтын» чыгаруга квоталар арттырыла, әмма күпчелек илләр бирелгән иркенлектән файдалана алмыйлар. Алар арасында үз квотасын үти алмаучы Россия дә бар.

Россиядә

СӨТ ҺӘМ ИПИ КЫЙММӘТЛӘНӘ

Россия җитәкчелегенә тышкы һәм эчке кыенлыклар белән даими көрәш алып барырга туры килә. Британиядә Мәскәүгә каршы киңәйтелгән санкцияләрне 10 февральгә кадәр үк кабул итеп бетерергә җыеналар. Кремльдә яңа тыюларны Россия бизнесына һөҗүм дип бәяләп өлгерделәр инде. «Газ сугышы» дип аталган корал сәяси җитәкчелек теләгән нәтиҗәне бирми. Европада инде 9 атнадан ягу сезонын төгәлләргә җыеналар, туңучылар күренми. Кыш алай ук салкын килмәде, Көнбатыштагы газ саклагычларда 39 миллиард кубометр газ бар, бу аларга кышны чыгарга җитәчәк. Себер газын Көнбатышка озатуны киметү базарны югалтуга гына китерде. Гыйнвар аенда Россия Европага 7,2 миллиард кубометр газ озаткан булса, башында АКШ торган сыек газ коалициясе 10,36 миллиард кубометр «зәңгәр ягулык» китергән. Февраль аенда «Газпром» бәяләрне төшерергә тиеш, бу аңа Европа базарында лидерлыкны кире кайтарыр, бәлки.

Бәяләргә каршы көрәш фронтында да уңышсызлыклар көтелә. Сөт һәм ипи җитештерүчеләр инфляциянең яңа дулкынын вәгъдә итәләр. Моңа гаҗәпләнергә кирәкми, чөнки бер генә тармакны богаулап, бәя күтәрмичә тору мөмкин түгел. «Российская газета»ның сишәмбе саны, үткән ел кәбестә бәясе 4 тапкыр үсте, быел да аңа бәя күтәрелү дәвам итә, дип яза.

Россиядәге сөт продуктлары җитештерүче иң зур компания – Danone («Простоквашино» һәм «Активиа» брендлары белән танылган) ритейлерларга февраль аеннан сөтне 10 процентка кыйммәтләндереп озатачагын хәбәр итте. Компания сөт продуктларына биржа бәяләренең максималь югарылыкта булуына игътибарны юнәлтә: ел эчендә майга бәя – 45, төргәкләү чыгымнары – 6,9, логистика чыгымнары 6,7 процентка кыйммәтләнгән. Башка компанияләр дә моның белән килешә. Эшкәртелмәгән сөтнең үзкыйммәте 15–20 процентка артуын әйтәләр. Хәер, сөтне төп җитештерүчеләргә сүз бирсәләр, алар сыер имчәгеннән савып алынган сөтнең үзкыйммәте 2–3 тапкыр артуы турында сүз алып бара алырлар иде, мөгаен.

Ипи пешерүчеләр дә сөт җитештерүчеләрдән калышмаска вәгъдә итәләр. Fazer Group дигән компания үз продукциясенә бәяләрнең 16,5–30 процентка артачагын әйтә. Компанияләрнең исемнәрен генә карагыз. Болар – Россия базарын үз кулларында тотучы чит ил компанияләре. Соңгысы, мәсәлән, фин җитештерүчесе. Аңлашыла инде: боларны базарда административ кыскычлар белән көчләп тота алмыйсың. Авылдагы сыер савучының гына китәр җире юк. Болар табыш булмаса, базарны ташлый да китә.

Ипи һәм сөт кенә түгел, башка продуктлар да сикерешле кыйммәтләнә. Газлы су һәм кофе җитештерүчеләр 25 процентка кадәр бәя өстәргә вәгъдә бирәләр.

tatarstan.ru

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Рөстәм Миңнеханов Чаллыга эшлекле сәфәр кылды. Сәфәрнең төп максаты – «КамАЗ» гавами акционерлык җәмгыятенең Россия Фәннәр академиясе белән хезмәттәшлек итү мәсьәләсенә багышланган киңәшмәдә катнашу. Әлеге чарада Россия Фәннәр академиясе президенты Александр Сергеев, КамАЗ генераль директоры Сергей Когогин катнашты.

Президент Рөстәм Миңнеханов утырышта машина төзү тармагы алдындагы бурычларны искә төшереп үтте. «КамАЗ бүген илнең машина төзү тармагында алдынгы сафларда баручы компания булып тора, – диде ул. – Соңгы еллар эчендә күп эшләнде. Алдынгылыкны саклап калу өчен фәнни казанышлардан файдалану кирәк. Юкса авыр булачак».

Киңәшмә барышында, Фәннәр академиясенең фәнни-тикшеренү казанышларына һәм кадрлар мөмкинлегенә таянып, электр һәм водород транспортын, «акыллы» транспортны үстерү мәсьәләләре каралды.

Рөстәм Миңнеханов һәм Александр Сергеев катнашында узган очрашуда исә Россия Фәннәр академиясе белән хезмәттәшлек, сәнәгать һәм машина төзелешендә фәнни эшләнмәләрне куллану мәсьәләләре турында фикер алыштылар. Моннан тыш, Татарстанда академик фән үзәге («Академшәһәрчек») булдыру концепциясе хакында да фикер алыштылар. Республикада заманча академик фән үзәген булдыру идеясе беренче тапкыр 2020 елда Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәгенең 75 еллыгын бәйрәм итү кысасында яңгырады.

ФОНДНЫҢ – ЭШЕ, ӨЛКӘННӘРНЕҢ ПЕНСИЯСЕ АРТА

Нәтиҗә

2022 елда Татарстанда уртача пенсия күләме 17,8 мең сум булачак. Исегезгә төшерәбез: Россия Президенты Владимир Путин пенсияләрне инфляциядән югарырак итеп – 8,6 процентка индексацияләргә тәкъдим итте. 1 февральдән айлык акчалата түләү (ЕДВ), апрель башыннан социаль пенсияләр дә арта. Август аенда 2021 елда эшләгән һәм алар өчен иминият кертемнәре түләнгән пенсионерларның пенсия күләме үзгәрә. Бу хакта Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин еллык киңәйтелгән утырышта сөйләде.

– 2020 елдан Пенсия фонды берничә төр хезмәт күрсәтүне гадиләштерде. Пенсия һәм пособиеләр читтән торып кына рәсмиләштерелә башлады. Моңа кадәр билгеләнгән түләүләр автомат рәвештә озайтылды. 2022 елда бу эш дәвам итәчәк, – диде ул.

Быелдан, пенсия түләүнең яңа кагыйдәләре буенча, банкрот дип танылган пенсионерлар кредит түләүдән азат ителәчәк. Шулай ук пенсия алуны гариза язып, мөрәҗәгать итмичә генә рәсмиләштерү исемлеге дә киңәйтелгән. 2022 елда инвалидлык буенча пенсияләр һәм федераль социаль өстәмә түләүләр Пенсия фондына мөрәҗәгать итмичә, тиешле статусны ачыклау факты буенча билгеләнәчәк.

Эдуард Вафин тагын бер яңалыкка тукталды. Эшләмәүче кешеләрне эшкә урнаштыру мөмкинлеге булмаса, мәшгульлек үзәге тәкъдиме буенча, андыйларга вакытыннан алда пенсия билгеләргә мөмкин.

– Туендыручысын югалтканга иминият пенсиясе алучы 80 яше тулган кешеләргә пенсиянең иң отышлы варианты автомат рәвештә сайлана. Кайсы файдалы – шунысын билгелиләр. Кемгәдер ул картлык буенча иминият өлеше, кем өчендер туендыручысын югалтканга бирелә торган өстәмә түләү булачак. Моннан тыш, «авыл өстәмәсе» буенча пенсия алучылар саладан башка җиргә күченгән очракта да бу акчаны алачак, – диде Эдуард Вафин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Пенсия фонды эшчәнлегенә бәйле тагын үзгәреш бар. 2022 елда фонд аша күп кенә түләүләрне билгели башлыйлар. Быелдан балаларга пособиеләр, радиациядән зарар күрүчеләргә мәҗбүри түләүләр, репрессия корбаннарына, хәрби хезмәткәрләрнең балалы хатыннарына пособиеләр, инвалидларга ОСАГО буенча компенсация бирүне Пенсия фонды башкарачак. Мондый ярдәмне республикада 21 меңнән артык кеше алачак. Түләүләр өчен 141,5 миллион сум тотылачак. Әлеге түләүләр «бер тәрәзә» принцибы буенча башкарыла һәм бөтен илдә бердәм кагыйдәләр буенча билгеләнә. Болай эшләү хезмәт күрсәтүнең сыйфатын арттырырга, ә халыкка документлар җыймыйча гына пособие алырга мөмкинлек бирәчәк.

Эдуард Вафин пенсиягә чыгасы гражданнар белән алдан эшләү хакында да, инвалидлыкка бәйле түләүләрне билгеләүгә дә тукталды. Бу эштә медицина мәгълүмат-аналитика үзәге белән бергәләшеп эшлиләр. Әйтик, инвалидлыкны юллап йөргәндә үк, Пенсия фондына хәбәр килә. Шуңа нигезләнеп, бу кеше гариза да язмыйча, аңа пенсия билгеләнә.

Эдуард Вафин «Ана капиталы» программасы хакында да сөйләде.

– Әлеге программа эшли башлаганнан бирле, гаиләләр өчен 111 миллиард сум акча җибәрелде. 2021 елда республикада 355 мең гаилә ана капиталы алды. Татарстан Пенсия фонды бу акчадан файдаланырга рөхсәт сорап язылган 30 меңнән артык гаризаны канәгатьләндерде. Аларның гомуми суммасы 12,5 миллиард сум тәшкил итте. Гаризаларның 72 проценты торак шартларын яхшыртуга туры килә, – диде ул. – Бу акчадан айлык түләү алучы гаиләләр саны арта. 2020 ел белән чагыштырганда акча сорап мөрәҗәгать итүчеләр саны 30 процентка арткан. Узган ел 4335 гаилә 200 миллион сум акча алды. 1 февральдән ана капиталын индексацияләү инфляция буенча үткәреләчәк. Беренче бала туган очракта гаилә 524527,9 сум алачак. Икенче бала туса, капитал күләме 168616,2 сумга арттырыла.

Утырышта катнашкан Татарстан Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева районнарда пенсия яшендәгеләрне яңадан укыту проблемасына тукталды. Әгәр укыту оештырылмаган районнар бар икән, бу эшне тиз арада башкарырга кирәк, диде ул. Премьер-министр урынбасары ана капиталына торак алгандагы күңелсез хәлләр турында да искә төшерде.

– Кеше йорт сатып ала икән, торак яшәргә яраклы, сыйфатлы булырга тиеш. Кайчак бу эштә каршылыклар булса, без аны кабул итмибез. Ә бит чынлыкта, акчасын түләгәч, яхшы торак булырга тиеш, – диде ул.

Ләйлә Фазлыева, узган ел пандемия шартларында халык белән эшләгән өчен Пенсия фонды һәм күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренә рәхмәтен дә белдерде.

– Ни дисәк тә, җанлы сөйләшүгә җитми инде. Кеше кая гына ярдәм сорап килмәсен: Пенсия фондынамы, башка җиргәме – ул аннан күтәренке кәефтә китәргә тиеш. Быелгы Цифрлаштыру елы күп кенә эшләрдә җиңеллек, оперативлык китерәчәк, – диде ул. – Узып киткән ел җиңел булмады. Өлкәннәргә ярдәм йөзеннән «Без бергә!» волонтерлар хәрәкәтен оештырдык. Дөрес, кимчелекләр дә бардыр, әмма безгә пандемия шартларында бу эшне дәвам иттерергә кирәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КОТКЫГА БИРЕЛМИБЕЗ

Авыл хуҗалыгы

Узган ел көнбагыш мае, шикәр, онга бәя аеруча нык арткан. Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Наил Залаков әнә шулай дип белдерде.

– Бәяләр чимал кытлыгы аркасында артты. Узган ел белән чагыштырганда, республикада чистартылмаган (нерафинированный) көнбагыш мае җитештерү 20 процентка кимегән. Шулай ук узган ел шикәр комына да бәяләр кинәт өскә сикерде. Әлеге продуктларга бәяләр Татарстанда гына түгел, бөтен Россиядә артты, – дип белдерде министр урынбасары.

Шуңа күрә бәяләрне йөгәнләр өчен җитештерүчеләргә өстәмә акча бүлеп бирелде. Мәсәлән, көнбагыш мае җитештерүчеләр – 206,6 млн, шикәр комы җитештерүчеләр – 14,4 млн, он җитештерүчеләр бодай эшкәртер өчен – 66,6 млн, икмәк пешерүчеләр 64,6 млн сум акча алган. «Бәяләрне тотрыклы саклар өчен ярминкәләрнең дә өлеше зур булды», – диде Наил Залаков.

– Болардан тыш, быел без әлеге культуралар (шикәр чөгендере, көнбагыш) мәйданын 12 процентка арттырырга планлаштырабыз. Моның өчен фермерларга, хуҗалыкларга дәүләт ярдәмнәре тәкъдим итәбез, – диде министр урынбасары.

Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, ел авыр булуга карамастан, министрлыкның эшчәнлеген югары бәяләде.

– Мин үзем шуннан килгән кеше буларак, әйтәсе килгән фикерем бар, – дип башлады ул сүзен. – Узган ел авыл хуҗалыгы бик җитди сынау кичерде, ләкин министрлыкның системалы, эзлекле, товар җитештерүчеләр белән киңәшле эш алып баруы нәтиҗәсендә тармак бу имтиханда сынатмады. Керем 2020 ел белән бер дәрәҗәдә калды. 5 млн урынына 2,5 млн тонна уңыш җыеп алу кесәгә бик нык сукса да, бүгеннән үк язга актив рәвештә әзерлек бара. Бу, әлбәттә, кәефкә, аерым бер бизнес-проектларга йогынты ясаячак, ләкин коткыга бирелү юк.

Марат Әхмәтов терлекләрнең кышны яхшы чыгуын, минераль ашламалар туплануын, сөт күләменең артуын билгеләп узды.

Утырышта шулай ук сукбай этләр темасы да күтәрелде. Комитет рәисе Азат Хамаев билгеләп узганча, тиздән Дәүләт Советы Президиумының күчмә утырышын уздыру планлаштырыла. Анда хайваннарга җаваплы карау турындагы федераль законның положениеләрен гамәлгә ашыру мәсьәләсен һәм хайваннарга мөнәсәбәт буенча кайбер мәсьәләләрне җайга салу турындагы республика законын карарга уйлыйлар.

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Илдар Нугуманов әйтүенчә, монда сүз йорт хайваннарын мәҗбүри рәвештә теркәү һәм ул булмаган очракта, җаваплылык булдыру, шулай ук фатирда һәм шәхси йортларда аларны асрау белән бәйле яңа таләпләр кертү турында барачак.

– Сукбай этләргә бәйле вазгыять бик күп төбәкләрне борчый, – диде Азат Хамаев. – Этләр зурларга да, балаларга да һөҗүм итә. Фаҗига белән тәмамланган очраклар да бар. Алда безне зур эшләр көтә. Бу законга да, норматив хокукый актларны тәртипкә китерүгә дә карый.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

2021 ЕЛДА ЯШЕЛЧӘ БӘЯЛӘРЕНДӘГЕ ҮЗГӘРЕШЛӘР

Продукция исеме	Ваклап сату (сум)			Бәяләрдәге үзгәрешләр			
	20.07. 2020	11.01. 2021	19.07. 2021	Ел башына (сум, процент)		Узган ел белән чагыштырганда (сум, процент)	
Бәрәңге	31,0	27,0	44,6	+17,5	164,9	13,5	143,6
Кәбестә	22,6	16,8	41,6	24,8	247,6	19,0	183,9
Суган	30,8	25,7	32,4	6,7	125,9	1,5	105,0
Кишер	40,8	25,8	85,1	59,3	329,5	44,3	208,7

«Татар-информ» / Владимир Васильев

РӨХСӘТСЕЗ ТУН ДА ЧИКТӘН УЗМЫЙ

Коронавирус дип тормаганнар, чикне ешрак кичкәннәр. Пандемиягә карамастан, товар әйләнеше дә үскән. Чик аша тыелган товарларны алып чыгу очраклары да бөтенләй булмаган түгел. Татарстан таможнясы узган елга хисап тотты.

Коронавирус инфекциясен, илләр арасындагы чикләрнең берникадәр ябылып торуын исәпкә алып, таможня вәкилләре телгә алачак саннар бик үк сөендерерлек булмас төсле иде. Әмма Татарстан таможнясы җитәкчесе Марат Гәрәев киресен дәлилләде.

– Дөньядагы эпидемиологик вазгыятьнең киеренке булуына карамастан, республиканың товар әйләнеше, узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, артты, – диде ул. – 2021 елда бу күрсәткеч 16 млрд долларга җиткән икән (үсеш – 4 млрд долларга). Әйтик, 2020 елның гыйнвар – декабрь аралыгында ул 12 млрд доллар тирәсе булган. 16 млрд долларның 10 миллиардтан артыгы – экспорт, калганы импортка туры килә. Сүз уңаеннан, Идел буе федераль округының тышкы сәүдәсендә республиканың өлеше 29 процентны тәшкил иткән. 2021 елда Татарстан таможнясы федераль бюджетка 2,7 млрд сум акча күчергән.

Марат Гәрәев әйтүенчә, былтыр таможня хезмәте товарларга 1421 декларация төзегән. 6017 таможня тикшерүе уздырганнар, шуларның 5 меңнән артыгы товарларны халыкара почта хезмәте аша җибәргән вакытта оештырылган.

Үсешне керемдә генә түгел, кеше санында да сизгәннәр. Әйтик, былтыр, пандемиянең кырыслыгына карамастан, пассажирлар саны бермә-бер арткан. Марат Гәрәев әйтүенчә, бу күрсәткеч «Бигеш» аэропортында – 3, Габдулла Тукай исемендәге «Казан» аэропортында 2 мәртәбә үскән.

Сыйфатсыз товарлар мәсьәләсенә килгәндә, Марат Гәрәев әйтүенчә, былтыр таможня хезмәткәрләре 16,7 тонна маркировкасыз азык-төлек товарын әйләнештән алган. Бу – 1,7 млн сумлык продукция дигән сүз. «Гадәттә, бу – чикләвек, яшелчә, җиләк-җимеш, сыр, ярма, киптерелгән җимешләр. Товарларны саклау шартлары, кайда һәм кайчан җитештерелгән булуы турында мәгълүматлар, ЕАС билгесе булмаганга күрә әйләнештән алабыз», – дип аңлатты таможня җитәкчесе.

Азык-төлектән тыш, тун, аяк киеме, спорт костюмы, тәмәке продукциясе, урын-җирләргә дә шундый ук язмыш язган. Марат Гәрәев сүзләренчә, таможня хезмәткәрләре әйләнештән 44071 данә шундый товарны алган. Иң кызыгы – шуларның 43 меңнән артыгы тәмәке продукциясенә туры килә.

Таможня хезмәткәрләре былтыр өч контрабанда очрагын булдырмый калган.

– Россия гражданнары саналган ике егет Төркиягә 62 һәм 70әр мең доллар күләмдә акча алып чыкканда тотылды. Аларга җинаять эше кузгатылды. Аларга гаепләү карары чыкты инде: акчалары тартып алынды һәм бер елга ирекләре чикләнде. Тагын бер җинаять эше Төркиядән законсыз рәвештә зәркән эшләнмәләрне күчергән өчен кузгатылды. Бу эш буенча тикшерү эшләре бара әле, – дип сөйләде әлеге очраклар турында Марат Гәрәев.

Гомумән алганда, Татарстан таможнясы 1950 административ, 17 җинаять эше кузгаткан. Соңгысы күп очракта наркотик һәм психотроп матдәләргә, таможня акчасын түләмәүгә бәйле икән.

ЭШЛӘГӘН ӨЧЕН УТЫРТМЫЙЛАР

Хокук саклау

Үз көннәрен үзләре күрәчәкләр. Россиядә хөкем ителгән кешеләр өчен киләчәктә 100 мең мәҗбүри эш урыны булдырырга ниятлиләр. Татарстанда андыйларга ике ел дәвамында 1500гә якын урын әзерләргә җыеналар. Ирегеннән мәхрүм ителүчеләр санын киметүдән бигрәк, утырып чыкканнарны гадәти тормышка әзерләү максат итеп куела. Шул рәвешле кабат җинаять кылу очракларын киметү теләге дә бар.

Бу атна башында Россия Президенты Владимир Путин белән очрашуда юстиция министры Константин Чуйченко да әнә шул хакта сөйләгән. Хәзерге вакытта илдәге төзәтү учреждениеләрендә 350 мең кеше тотыла. Закон буенча шуларның 180 меңе мәҗбүри эшкә күчерелүгә өметләнә ала. Дөрес, моның өчен суд карары, бу кешеләрнең тиешле шартларга туры килүе, ә иң мөһиме, аларның үзләрендә теләк булу кирәк. Әмма бу да җитми. Константин Чуйченко әйтүенчә, хезмәт белән төзәлү юлына баскан кешеләрне тоту өчен урын кирәк. «100 мең чамасы кеше иректән мәхрүм итү урынына мәҗбүри эшкә җибәрелергә лаек дип саныйбыз. Безнең 15 мең урын әзерләнгән, 2024 елга бу санны 100 меңгә җиткерү теләге бар», – дигән юстиция министры. Кремльнең матбугат үзәге хәбәр итүенчә, Владимир Путин бу фикер белән килешкән.

"ВТ" архивыннан

Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе мәгълүматларына караганда, хәзерге вакытта Казандагы төзәтү үзәгенә мәҗбүри эшкә хөкем ителгән 307 кеше беркетелгән. 50 се – хатын-кызлар. Алар азык-төлек, әйтик, икмәк пешерү заводында, агач эшкәртү, төзелеш, ТКХ оешмаларында эшли. Түбән Камадагы 4 нче төзәтү колониясе карамагындагы үзәктә 100 кешелек урын бар. Республикада мәҗбүри эшкә хөкем ителгәннәр өчен быел өстәмә 400 урын әзерләргә, ике елдан исә бу санны 1500гә җиткерергә ниятлиләр. «Мәҗбүри эш урыннарын Чаллыда да булдыру теләге бар. Моның өчен идарәнең генә мөмкинлеге җитми. Предприятиеләр белән сөйләшүләр алып барабыз, дәүләттән ярдәм сорыйбыз», – ди Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе бүлек җитәкчесе Айрат Хәбибуллин. Сүз уңаеннан, республикада ирегеннән мәхрүм ителгән 3600 кеше мәҗбүри эшкә күчерелүгә өметләнә ала.

Бу очракта сүз төрмә-колонияләрдә утыручылар санын киметү турында гына түгел, ә хөкем ителгәннәрне, кем әйтмешли, тыныч тормышка әзерләү турында да бара. Билгеле факт: кабат җинаять кылучыларның күбесе – иреккә чыккач, ни эшләргә белми аптырап калучылар. Айрат Хәбибуллин әйтүенчә, мәҗбүри эшкә хөкем ителүчеләргә әнә шул сынауны узу мөмкинлеге бирелә. Алар көн саен үзләре эшкә йөри, минималь хезмәт хакы күләменнән аз булмаган акча ала. Кыскасы, үз көннәрен үзләре күрергәияләшә. Моннан тыш, бу кешеләр туганнары белән ешрак аралаша ала. Хәтта ял вакытында өйләренә кайтып килү, эшләгән оешма-предприятие урнашкан район яки шәһәрдә гаиләсе белән яшәү мөмкинлеге дә рөхсәт ителергә мөмкин.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Уйлы күңел уйлана

Исраф итәсе түгел

Кышкы авылның зыкылы иртәсе. Кояш бераз күтәрелгәч, бәрәңге бакчасына чыгып бастым. Саф һавада, карт сөякләрне язып, кар өстендә йөрүләре бик рәхәт. Шулвакыт тыкрыктан үтеп баручы танышым туктады. Хәл-әхвәл сораштык та, ул, сәгатенә карап, ашыгуын әйтте.

– Азнакайга барып кайтам, бер сыңар ботинканы ремонтлатырга иде, – дип китеп тә барды.

Шуннан ирексездән уйлар йомгагына уралдым. Яшь-җилкенчәк, ике-өч киюгә, модасы чыкты дип, берни булмаган киемен чүплеккә ташлаган заманда, син сыңар ботинкаңны ремонтлатып йөр: машинаң белән барып-кайтып, янә төзәткән өчен фәлән сумны җыйсаң, яңаны алганың бишләтә файдага бит югыйсә. Юк шул, безнең буын кешеләрендә сакчыллык төшенчәсе канга сеңеп калган, һич тә әйберне әрәм-шәрәмгә – исрафка чыгара торган түгел!

Чана юлы

Без, укыганда, кышларын авыл башындагы мәктәбебезгә иртә таңнан тирә-күрше терлекче абыйлар-агайларыбыз салган атлы чана эзеннән җай гына атлап йөри идек. Язга тикле тәмам такыраеп кала иде ул. Хәзерге кебек урамыңны чистартып-эттереп китүче куәтле техника төшкә дә керми иде ул чакта. Бүген исә нинди зур урамыбызда бер генә атлы эштә эшләүчене дә, ат асраучыны да күрмәссең. Атлы чана юлы үзе түгел, бәләкәй чана эзе чалынса да, урам җанланып киткәндәй булыр иде әле. Хәер, малай чактагы сыман өй рәтеннән дистәләгән бала-чага тулып ятмый шул хәзер. Безне бабайлар мунчасына да кышларын әнинең энесе Харис абыебыз, киемнәребез җитмәгәч, атлы чанага җәелгән толыпларга алтыбызны төреп, шул олы чана юлыннан ташып, җәһәт кенә юындырып-чистартып кайтара иде, рәхмәт төшкере!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы Сәпәй авылы

Белдерү

Кадастровым инженером Ирбулатовым Маратом Рафиковичем (почтовый адрес: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д. 1, контактный тел.: 89600488084, электронная почта marat_327@mail.ru, № квалификационного аттестата 16-15-841), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:24:259901:51, расположенного по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Столбищенское сельское поселение, некоммерческое коллективное садоводческое товарищество «Танкист», выполняются кадастровые работы по уточнению границ земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Куршев Алексей Владимирович (почтовый адрес: 420059, Республика Татарстан, г. Казань, военный городок 33, д. 6, кв. 80).

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться в будние дни с 10.00 до 18.00 ч. по адресу: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д.1.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ земельного участка состоится по адресу: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д. 1 3 марта 2022 года в 10 часов 00 минут.

Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются со дня опубликования в печатном издании в течение месяца по адресу: 420100, г. Казань, ул. 2-ая Азинская, д.1.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы земельного участка: 16:24:259901:633; 16:24:259901:65; 16:24:259901:50; 16:24:259901:715 (земли общего пользования).

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе хезмәткәрләре: дәүләт экология экспертизасы һәм рөхсәт бирү эшчәнлеге төбәкара бүлеге башлыгы **Попова** Елена Евгеньевна, дәүләт экология күзәтчелеге бүлеге башлыгы урынбасары **Филиппов** Василий Николаевич, дәүләт экология күзәтчелеге бүлеге башлыгы **Хисмәтуллина** Кадрия Латфулла кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«ТаграС-РемСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең корпоратив коммуникацияләр буенча баш белгече **Ежова** Светлана Викторовнага, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыятенең телевидение музыкаль һәм әдәби программалар баш редакциясе мөхәррире **Мәһдиева** Әлфирә Әдһәм кызына, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыятенең телевидение «Семь дней» иҗат берләшмәсе махсус проектлар мөхәррире **Юзаева** Илзирә Зөфәр кызына **«Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Рәсми документлар

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАР

27 гыйнвар, 2022 ел Казан ш. № 165/1405

2021 елның декабрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен раслау турында

Тиешле мәгълүматны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен билгеләү буенча Эш төркеменең «2021 елның декабрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләре турында» 11 гыйнвар, 2022 ел, № 96 карарын тикшергәннән соң, «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 11 ноябрь, 2010 ел, № 35/392 карары белән расланган Төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген бер календарь ае эчендә яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү тәртибенең VI бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 2021 елның декабрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен (Эш төркеменең 11 гыйнвар, 2022 ел, № 96 карарында урын алган) расларга.

2. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалының 2021 елның декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

3. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» – «Болгар» радиосы» радиопрограммасы төбәк радиоканалының 2021 елның декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

4. Бу карарны «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә җибәрергә.

5. Бу карарны бастырып чыгару өчен «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштырырга.

6. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары О.В.Сквордяковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

27 гыйнвар, 2022 ел Казан ш. № 165/1406

2021 елда «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалында һәм «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртканда аларның тигезлеге гарантияләрен тәэмин итү турында мәгълүматларны раслау хакында

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары О.В.Сквордяковның мәгълүматын тыңлаганнан соң, «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 11 ноябрь, 2010 ел, № 35/392 карары белән расланган Төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген бер календарь ае эчендә яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү тәртибенең VIII бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 2021 елда «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалында һәм «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртканда аларның тигезлеге гарантияләрен тәэмин итү турында мәгълүматларны (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Бу карарны «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә җибәрергә.

3. Бу карарны бастырып чыгару өчен «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтына урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясенең
27 гыйнвар, 2022 ел, № 165/1406
карарына кушымта

2021 елда «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалында һәм «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртканда аларның тигезлеге гарантияләрен тәэмин итү турында мәгълүматлар

Ел ае	Телеканал, радиоканал	Сәяси партияләр атамасы	
		«Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясе	«Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясе
		Эфир вакыты күләме (сәгать:минут:секунд)	
гыйнвар, 2021 ел	телеканал	0:34:35	0:34:28
	радиоканал	0:34:20	0:34:16
февраль, 2021 ел	телеканал	0:32:45	0:32:39
	радиоканал	0:34:23	0:34:19
март, 2021 ел	телеканал	0:34:23	0:34:16
	радиоканал	0:31:38	0:31:36
апрель, 2021 ел	телеканал	0:35:29	0:35:20
	радиоканал	0:33:46	0:33:39
май, 2021 ел	телеканал	0:36:54	0:36:49
	радиоканал	0:35:01	0:34:59
июнь, 2021 ел	телеканал	Сайлау кампаниясен үткәрү чоры	
	радиоканал		
июль, 2021 ел	телеканал	Сайлау кампаниясен үткәрү чоры	
	радиоканал		
август, 2021 ел	телеканал	Сайлау кампаниясен үткәрү чоры	
	радиоканал		
сентябрь, 2021 ел	телеканал	Сайлау кампаниясен үткәрү чоры	
	радиоканал		
октябрь, 2021 ел	телеканал	0:40:25	0:40:28
	радиоканал	0:37:32	0:37:34
ноябрь, 2021 ел	телеканал	0:42:08	0:42:05
	радиоканал	0:36:33	0:36:25
декабрь, 2021 ел	телеканал	0:45:01	0:44:56
	радиоканал	0:37:14	0:37:09
Ел дәвамында барлыгы	**телеканал**	**5:01:40**	**5:01:01**
	радиоканал	**4:40:27**	**4:39:57**

Укып сөенсеннәр!

Автор фотосы

Бәйге

Киштәдә дә, укучы күңелендә дә урын алырга лаеклы. Татарстан Язучылар берлегендә Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тәкъдиме белән игълан ителгән ябык әдәби конкурсның «Роман» номинациясендә җиңүче авторларны атадылар. Конкурсның шул ягы да кызык: жюри вәкилләренә әсәр үзе һәм хуҗасының тәхәллүсе генә билгеле иде.

Моңа кадәр конкурсның шигърият һәм прозаның башка жанрларына караган юнәлешләре җиңүчеләрен ачыклаганнар иде. «Роман» номинациясенә соңрак тотынганнар.

Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла әйтүенчә, конкурста катнашучыларның иҗади эшләре белән 9 кешедән торган жюри танышкан. Алар арасында әдәбият галимнәре һәм язучылар булган. «Роман» номинациясенә 15 эш кабул ителгән. Бишесен сайлап алганнар. Шулар арасыннан 3 җиңүчене билгеләгәннәр.

1 урын – Зөлфәт Хәким, «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?» (Казан);
2 урын – Фирдүс Гыймалтдинов, «Урда ханы Үзбәк» (Казан);
3 урын – Равил Сабыр, «Фәхрине үтереп ташладылар» (Әлмәт).

– Әйтик, Фирдүс – безнең өчен бөтенләй көтелмәгән автор. Тарихи романы җиңеп чыкты. Төзелеше искиткеч камил, безгә бик ошады. Тарихи әсәрләр безгә бик кирәк, – дип бәяләде иҗади эшләрне Ркаил Зәйдулла. – Хәзерге заманны тасвирлаган әсәрләр дә шактый булды. Ә менә Зөлфәт Хәким язган романда ике чор параллель бара. Төп сюжет сызыгы – кешелеклелек. Кеше гуманистик принципларын югалтмаска тиеш. Шушы мәңгелек фәлсәфи нәтиҗәне чыгарган автор. «Фәхрине үтереп ташладылар» романында да әхлакый сыйфатларга урын бирелә. Бу әсәрләр «Казан утлары» журналында басылып чыгачак. Минемчә, халык аларны күреп сөенер һәм бүгенге татар прозасы белән горурланыр.

«Казан утлары» журналы баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин сүзләренчә, җиңүче әсәрләрнең әлеге басмада урын алуы конкурсның бер таләбе иде. Димәк, әсәрләр чынлап та лаеклы, әдәби яктан камил булырга тиеш.

– 15 романның җиде-сигезе безнең журналда бастырырлык, дип нәтиҗә ясадым үзем өчен. Беренче урынга чыккан әсәрне бүген үк бастырырга әзербез. Ул «Казан утлары»ның июль – август саннарында басылачак. Менә дигән әсәр! Жюри вәкиле буларак укый башлаган идем, гади укучы буларак эченә кереп киттем, – диде Рөстәм Галиуллин.

Җиңүчеләрдән берсенең – «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе директоры Фирдүс Гыймалтдиновның шатлыгын «ВТ» да уртаклашты. Хезмәттәшебез яшерми: җиңү теләге булмаган түгел.

– Көткән, өметләнгән идем. Ябык конкурс булгач, комары да бар бит. Әсәрне язганда, үзеңнекен яхшы дип язасың инде ул. Язып җибәргәч, кат-кат укып чыктым, үземә ошамаган урыннарны таптым. Әле әсәрне бастырып чыгарганчы, ул урыннарны төзәтеп чыгасы бар. Җиңүем – зур шатлык. Бердән, шушы конкурсны оештырып, безне селкетеп җибәргән Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясенә рәхмәт. Аннан, конкурсның финанс ягын кайгырткан Татарстан Президентына, жюри вәкилләренә аерым рәхмәт, чөнки 15 романны укып чыгу җиңел эш түгел ул, – диде Фирдүс Гыймалтдинов.

Тарихи роман язарга аны нәрсә этәргән соң? Үзе әйтүенчә, романында сурәтләгән шәхескә карата шәхси кызыксынуы зур булган. Әсәрне узган елның июлендә яза башлаган һәм ноябрь аенда төгәлләгән. Моңа кадәр дә шәхесне өйрәнгән, мәгълүмат туплаган, фәнни хезмәтләрдән, гыйльми журналлардан файдаланган. Шул ук вакытта автор бу әсәрне Үзбәк ханның биографиясе дип кабул итмәскә өнди.

– Мин, булган чыганакларга таянып, үзем күргәнчә яздым. Үзбәк хан – Алтын Урда дәүләтен югары дәрәҗәгә күтәргән кеше. Шул ук вакытта дәүләтнең артка тәгәрәве дә аның нәсел дәвамчыларына бәйле. Әсәрдә мин аның тирәсендәге хатын-кызларның йогынтысын күрсәтергә тырыштым, – дип сөйләде Фирдүс Гыймалтдинов. – Бу – мәхәббәт, хакимлектәге кешенең ялгызлыгы турында, бөтен кеше омтылган нәрсәләрнең бер көндә эреп юкка чыгу мөмкинлеген күрсәткән роман. Укучы ничек күрер, һәрхәлдә, мин шушылай күзалладым.

Сан

- Әдәби бәйгенең акчалата призының гомуми күләме – **3** млн **895** мең сум.
- Конкурска **1450** эш кабул ителгән.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ВЕРОНИКА ЯМАЛЕЕВА:

«ИНГЛИЗ ТЕЛЕН ДӘ ИНГЛИЗЛӘР УКЫТМЫЙ БИТ»

Чаллы шәһәренең 9 нчы мәктәбендә рус телле балаларга татар теленнән белем бирүче Вероника Ямалеева бу сүзләрне юкка гына әйтми. Чөнки ул үзе – мари милләтеннән. Башка телләрне өйрәнергә, хәтта укытырга да бернинди чикләр юк дип саный.

:: Вероника Владиславовна, шулай да инглиз теле ул – бөтенләй башка өлкә, бездә инглизләр яшәми бит. Ә татарлар күп...

– Татар телен өйрәнергә теләү хисе миндә бәләкәй чактан бар иде. Бәлки, ул Татарстанда туып үскәнгәдер, өстәвенә күп кенә туганнарым да татарча аңлый, сөйләшә. Дөрес, мин кечкенәдән өйрәнә алмадым, чөнки ул вакытта мәктәптә татар телен татар балаларына гына укыттылар. Төрле милләттән булгач, дусларым белән дә күбесенчә рус телендә аралаштык, өйдә марича сөйләштек.

:: Татар телен ничек өйрәндегез?

– Мин үземне белгәннән укытучы булырга хыялландым. Бәләкәй чакта гел «мәктәпле» уйный идек. 11 сыйныфны тәмамлагач, хәтта уйлап та тормадым: Чаллыдагы педагогия көллиятенә юл тоттым. Менә шунда җай чыкты да инде: тәҗрибә йөзеннән рус телле студентларны татар теленә өйрәтергә булдылар. Мондый мөмкинлек чыгуга шатланганымны белсәгез! Бу төркемгә нәкъ минем кебек татар теленә битараф булмаган укучылар җыелды. Шуңа күрә дә рәхәтләнеп, тәмен белеп укыдык. Кураторыбыз Роза Мидхәт кызы Абдуллина безне татар телен яратырга, нечкәлекләренә төшенергә өйрәтте. Мин аңа чиксез рәхмәтлемен. Шуннан Казан дәүләт педагогия институтының Чаллы филиалында укуымны дәвам итеп, татар теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлеге алып чыктым. Дүртенче сыйныфтан бирле белем алган мәктәбемә эшкә килдем. 20 ел үткәне сизелмәде дә, чөнки миңа авыр түгел, киресенчә, эшемнең нәтиҗәсе күренгәч, күңелем һәрвакыт сөенеч белән тула.

:: Мавыгып китеп, үз туган телегезне онытмагансыздыр дип беләм?

– Юк, әлбәттә. Гомумән, безнең туганнар арасында өч телне белү – гадәти күренеш.

:: Балаларыгыз нинди телдә сөйләшүне кулайрак күрә?

– Мәктәптә, урамда төп аралашу рус телендә булгач, алар да рус телендә күбрәк сөйләшә инде. Әмма татар телен дә, мари телен дә яхшы беләләр.

:: Тел мәсьәләсендә туган ягыгызда нинди хәлләр бар?

– Безнең якта марилар биш авылда күмәкләшеп яши. Минзәлә районында – Калтак, Филимоновка, Чупай, Мөслимдә Мари-Бүләр һәм Осиновка авыллары. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, алар анда берничә йөз еллар элек пәйда булган: Явыз Иван Казанны басып алган чорда килеп төпләнгәннәр. Шуңа, күрәсең, Татарстанда яшәүче мариларның үз диалектлары барлыкка килгән. Моны мари-татар диалекты дип тә атарга мөмкин булыр иде, чөнки алар күп кенә татар сүзләрен «үз иткәннәр». Мин бу фикерне күргәннәремнән чыгып әйтәм. Чөнки Йошкар-Олага баргач, мари телендә башкачарак сөйләшүләрен ишеттем. Ничек кенә булмасын, туган җиремдә марича сөйләшәләр, бәйрәмнәрне, төрле чараларны туган телдә үткәрәләр. Кыскасы, бөтен шартлар тудырылган.

:: Гадәттә, рус телле балалар татар теле дәресләрен өнәп бетермиләр. Бу өйрәнергә теләмәүдән дә түгел, беренче чиратта алар өчен артык эш, артык дәресләр кебек тоела бугай?

– Һәрхәлдә, минем укучыларым дәрескә бик теләп йөри. Күп нәрсә, чыннан да, укытучыдан тора бит. Мари милләтеннән икәнемне белгәч, балалар бигрәк тә кызыксынып китәләр. «Сез ничек шулай татар телен өйрәнә алдыгыз, җитмәсә укытасыз да әле?» – дип гаҗәпсенгән булалар. Андый вакытларда: «Инглиз телен дә инглизләр укытмый бит. Димәк, татар телен дә өйрәнергә була. Мин сезне өйрәтермен», – дип вәгъдә бирәм. Иң мөһиме, балаларны беркайчан да куркытмыйм. Контроль эш алдыннан алар: «Биремнәр авырмы?» – дип сорыйлар. Мин һәрвакытта да, юк, сез аларның барысын да беләсез инде, дип җавап бирәм. Беренче чиратта балада ышаныч тудырырга кирәк. Ахыр чиктә нәтиҗәсе дә әйбәт була. Татарча укый башлаганда, мин үзем дә берни белми идем бит. Үз башымнан үткәнгә, балаларны да ничек өйрәтергә икәнлеген бик яхшы аңлыйм.

:: Татар теле укытучыларыннан, дәреслекләр күбесенчә грамматиканы өйрәтүгә корылган, сөйләм теленә игътибар җитми, дигәнне ишеткәнем бар...

– Грамматикасыз сөйләм теленә дә өйрәтеп булмый бит инде. Нинди кушымчаның кайсы очракта кулланылганын өйрәтергә кирәк. Ә калганы, минемчә, укытучының осталыгына бәйләнгән. Дәреслекләрдән тыш интернетта да күп кенә файдалы материаллар табарга була. Әмма бу очракта, камиллеккә чикләр юк, дигән гыйбарә дә бик урынлы.

:: Сез нинди ысуллар кулланасыз?

– Дәресләргә иҗади якын килергә кирәк. Әдәбият дәресләрендә без әкиятләр укыйбыз, укучылар татар язучылары турында рефератлар язалар. Китаплардан гына түгел, интернеттан да файдаланалар. Фото һәм видеолар күрсәтү өчен һәр класска проекторлар куелган. Рус телле балалар булгач, әдәбият дәресләрендә татарча гына сөйләшүне таләп итеп куймыйм. Шуңа күрә киеренкелек тә пәйда булмый. Татар теле дәресләрендә исә балалар матур итеп сөйләшкәнне ярата. Без укып кына калмыйбыз, инсценировкалар ясыйбыз. Кызганыч, дәресләрне кыскарту сәбәпле, вакыт бик кысан. Шуңа күрә күбрәк әңгәмәләр алып барырга тырышам. Минемчә, сөйләшергә өйрәнү, чыннан да, телне өйрәнергә һәм яратырга нигез булып тора. Бу җәһәттән бер мисал китерәм. Күз алдына китерегез әле. Сез машина йөртү өчен теорияне өйрәнеп бетердегез, ди. Әмма рульгә утырмыйча, кызыксыну барлыкка килмәячәк. Ул гына да түгел, практика булмагач, сез өйрәнгәннәрне онытырга да мөмкинсез. Тел белән дә шулай. Кеше күпме кирәк сүз җыелмасы өйрәнергә, җыр тыңларга, кино карарга мөмкин. Әмма үзе сөйләшә башламаса, ул телне өйрәнә алмаячак. Шуңа күрә мин балаларны оялмаска, теләсә кайсы сүзне кычкырып әйтергә өндим.

:: Нәтиҗәләр...

– Укучыларым белемнәрен викториналарда, бәйгеләрдә күрсәтергә бер дә кыенсынып тормыйлар, ярышырга яраталар. Ел саен үткәрелә торган «Мин татарча сөйләшәм» шәһәр бәйгесендә призлы урыннарны алалар. Бер укучым Анастасия Матросова инде берничә ел туган тел буенча республика олимпиадасында катнаша һәм татар телен яхшы белүчеләр арасында исәпләнә. Быел үткәрелгән олимпиадада ике призерым бар.

:: Минем балам татар телен өйрәнергә теләми, дигән әти-әниләргә ни дияр идегез?

– Бу фикер дөрес түгел. Балаларны кызыксындырырга гына кирәк. Әти-әниләр дә моны яхшы аңласын иде.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ИЯРЕР ДИП УЙЛАМЫЙБЫЗ ДА...

Рәхмәт, табиб!

Бу авыру миңа иярер дип уйламадым да. Күрше авылда яшәүче бертуганым авырып киткәч, хәлен белергә бардым. Үземчә саклык чаралары да күрдем. Дөрес, ул чакта әле апада ковид булганын белмәдек. Берничә көннән тесты уңай кайта. Аннан соң да бардым. Шикләнмәгәч, иярмәс дип уйлап, янында сөйләшеп утырдык, чәйләр эчтек.

«Татар-информ»/Михаил Захаров

Икенче көнне инде үземнең температура күтәрелде. Башта 37 градус булды, аннан 38, 39... Бер атна буе температура төшмәгәч, тест бирдерттеләр. Уңай күрсәтә... Ул чакта әле районда компьютер томографы юк иде, «ашыгыч ярдәм» машинасы Сабага алып китте. Үпкәләр 15–20 процент зарарланган булып чыкты. Астма авырулы кеше буларак, сулыш алу сәгатьләп авырлашты. Шунлыктан район үзәк хастаханәсенә салдылар.

«Кызыл зона»га эләккәндә минем инде сөйләшерлек, җеп өзәрлек тә хәлем калмаган иде. Ярый әле анда бер җирдә дә чират торасы түгел. Палатага кереп, биш минут та үтмәгәндер, шәфкать туташлары янымда солдатлар кебек йөгерешә башлады: шул арада система куйдылар, сатурацияне үлчәделәр, уколлар кададылар... Башта аларны уйларлык хәлем булмады. Соңыннан инде анда эшләүчеләргә шаккатып яттым. Барысы да шулкадәр ипле, шулкадәр әйбәтләр... Иренмичә барысын аңлаталар. Махсус битлек астыннан ни хәлләр күрәләр, ничек тамырны табып, укол кадыйлар икән, дим...

Астма булганлыктан, хәлләр шактый катлауланды. Санаулы көн эчендә ике як үпкә дә 30 процентка зарарланган булып чыкты. Туганым: «Апа, кайгырма, Соловьев алып чыга сине. Ул – бик шәп табиб», – дип өметләндерде. Аңа кадәр әлеге табибка – үзебезнең районның Улисьял авылы егете Феликс Валерьевич Соловьевка эшем төшкәне юк иде. Ул, чыннан да, зур хәрефтән язылырга лаеклы табиб икән. Көне-төне шунда кунып эшли, ял көне дип тә тормый. Үзе ипле, үзе белемле, үзе һәр кеше белән якын итеп сөйләшә. Саф татарча! Аның тавышын ишетүгә, ул палатага килеп керүгә үк, үзеңә хәл кереп китә. «Балтач халкына игелек күрсәтер өчен кайткансың икән, энем», – дидем азактан. Биредә эшләүче Сәидәхмәд Гаипназаров, Рамил Җаббаров та – шулай ук искиткеч тырыш табиблар. Аларның ярдәмчеләре булган шәфкать туташлары, санитаркаларның куйган хезмәтләрен сөйләп бетерә торган түгел.

Иң авыры тәүлекнең 16 сәгатен корсакта яту булды. Калган вакытта бераз ял итеп, ян-якка борылырга ярый, әмма чалкан ятасы түгел. Күз алдына китерегез: бөтен кеше кислород битлегеннән, капланып яткан... Бер кешенең бер кешедә гаме юк. Коридорга чыгам дигән кеше дә, башкалар белән, хәтта танышлар белән сөйләшәм дигән кеше дә юк. Бөтен кешене дә бер төсле итә торган авыру бу. Әмма бөтенебездә дә тереләсе килү теләге бик көчле: барыбыз да табиблар кушканнарны төгәл үтәргә тырыштык. Безнең палатада дүрт кеше иде, шөкер, барыбыз да терелеп чыкты. Башта, хәлем авыр вакытта, куркасы дип тә белмәдем, күңелдә бу авыр халәт үтсен, бу газаплар тизрәк бетсен дигән теләк кенә иде. Ә менә терелә башлагач, ниләр кичергәнеңне кабат күңелеңнән үткәрәсең дә, чын-чыннан азагы турында уйлана башлыйсың. Әле бит авырдым да бетте түгел, минем очракта өчтән бере зарарланган ике як үпкәнең дә акрынлап булса да элекке хәленә кайтасы бар. Реабилитация срогы ике айдан ярты елга кадәр, диделәр. Ярый әле, рәхмәт төшкере, өйгә кайтып киткән чакта табибларым бик күп киңәшләр, дәвалар бирделәр.

Өйгә кайту әле ул терелеп беттем дигән сүз түгел шул. Көндәлек даруларны эчәргә, саклык чараларын күрергә кирәк. Бу авыру шикәрне дә күтәрә икән, күпләр, хәзер шуннан интегәбез, ди. Бездәге «кызыл зона» хастаханәнең балалар тудыру бүлегенә урнашкан. Шуннан чыккан чакта күңелемә бер теләк килде: «И, мин әйтәм, кайчандыр шушында хатын-кызлар бала тапкан, бала тудыру, әни булу бәхетенә сөенгән. Бу замана чире бетсен, юкка чыксын иде дә коридорлар кабаттан яңа туган сабыйлар авазына күмелсен иде», – дим. Авырмаучыларга бер генә теләгем бар: сакланыгыз! Бу – битарафлыкны гафу итә торган авыру түгел, бик мәкерле һәм катлаулы чир.

...Миңа иярмәс әле дип уйлаучыларга моннан да гади җавап була алмыйдыр.

Нурания КАЗАРЯН

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7080 данә
Гомуми тираж – 17126 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 215

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+